**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Судьяларның квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкиллегенә кандидатларны алдан сайлап алу тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Указына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Судьяларның квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкиллегенә кандидатларны алдан сайлап алу тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2002 елның 17 октябрендәге ПУ-880 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2020 елның 20 ноябрендәге ПУ-768 номерлы Указы һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 12 апрелендәге 233 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасы Судьяларның квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкиллегенә кандидатларны алдан сайлап алу тәртибе турында нигезләмәдә (алга таба – Нигезләмә):

2 пунктта:

беренче абзацта «(алга таба – оешмалар)» сүзләрен «(алга таба шулай ук – органнар, оешмалар)» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «Һәр оешмадан» сүзләрен «Һәр органнан, оешмадан» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта:

беренче абзацта «оешманың язма үтенечнамәсе» сүзләрен «органның, оешманың язма үтенечнамәсе» сүзләренә, «кандидатны тәкъдим иткән оешманың» сүзләрен «кандидатны (кандидатларны) тәкъдим иткән органның, оешманың» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «кандидатны» сүзеннән соң «(кандидатларны)» сүзен өстәргә;

унынчы абзацта «кандидатны тәкъдим иткән оешма» сүзләрен «кандидатны (кандидатларны) тәкъдим иткән орган, оешма» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Әгәр Татарстан Республикасы Судьяларның квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкиллегенә күрсәтелгән кандидатларның берсе дә Комиссия тарафыннан тәкъдим ителмәсә яки тәкъдим ителгән кандидатларның саны «Россия Федерациясендә судьялар берлеге органнары

турында» 2002 елның 14 мартындагы 30-ФЗ номерлы Федераль законга нигезләнеп билгеләнгән вәкиллек нормасы нигезендә кирәкле кандидатлар саныннан ким булса, Комиссия әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә алдан сайлап алуны тиешенчә кабаттан яисә өстәмә рәвештә уздыруны башлау турында карар кабул итә.»;

б) Нигезләмәгә 2 нче кушымтада:

6 пунктта «Мәгариф яисә фәнни учреждение» сүзләрен «Мәгариф оешмасы яисә фәнни оешма» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктның беренче абзацында «югары һәм урта махсус уку йортларында укуны» сүзләрен «югары белем бирү мәгариф оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 12 декабрь
№ 948